ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
II СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
II ЧАКЫРЫЛЫШ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июль, 2015 ел № 41/5

Техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтелүен бәяләү максатларында, биналарны һәм корылмаларны карап тикшерү тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтелүен бәяләү максатларында, биналарны һәм корылмаларны карап тикшерү тәртибе турында Нигезнамәне расларга.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының халык яшәешен тәэмин итү һәм шәһәр төзелеше буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазифаларын башкаручы Ф.И. Андреева

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
41/5 нче Карарына
кушымта
23 июль, 2015 ел

## Техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтелүен бәяләү максатларында, биналарны һәм корылмаларны карап тикшерү тәртибе турында Нигезнамә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Объектларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына техник регламент таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре нигезендә техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтелүен бәяләү максатларында, биналарны һәм корылмаларны карап тикшерү тәртибе турында әлеге Нигезнамә (алга таба – Нигезнамә) Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә эшләнгән.

2. Нигезнамә объектларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына техник регламент таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре нигезендә техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтелүен бәяләү максатларында, биналарны һәм корылмаларны карап тикшерү (алга таба – биналарны, корылмаларны карап тикшерү) тәртибен һәм оештыру процедурасын билгели.

3. Әлеге Нигезнамә биналарны, корылмаларны карап тикшергәндә кулланыла, мондый биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә федераль законнар нигезендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырылган очраклардан тыш.

### 2. Биналарны, корылмаларны карап тикшерүне оештыру, башкару

4. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү һәм мондый карап тикшерү барышында Россия Федерация Шәһәр төзелеше кодексы белән каралган очракларда ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында рекомендацияләр бирү шәһәр Башкарма комитеты (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Биналарны, корылмаларны эксплуатацияләүгә Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу турында, биналарда, корылмаларда аварияле хәлләр барлыкка килү турында физик яки юридик заттан күрсәтелгән биналар, корылмалар урнашкан урын буенча вәкаләтле органга гариза кергән очракта яисә биналарның,

корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килгәндә, биналар, корылмалар карап тикшерелә.

6. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү предметы булып аларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына техник регламент таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре нигезендә техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтелүен бәяләү тора.

7. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү бина, корылма урнашкан урын буенча төзелгән комиссия тарафыннан башкарыла.

8. Комиссия составы, аның эшчәнлек тәртибе Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

9. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү өчен экспертлар, эксперт яки башка оешмаларның һәм (яисә) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының вәкилләре җәлеп ителә.

10. Гариза бирүчегә һәм бина, корылманың хуҗасына яки законлы нигездә бинаны, корылманы биләүче затка вәкаләтле орган тарафыннан бинаны, корылманы карап тикшерү көненә өч эш көне кала, почта аша заказ белән җибәреп, тапшыру турында белдерү кагәзе белән яисә физик яки юридик затның карап тикшерүдә катнашу өчен гаризасында күрсәтелгән башка ысул белән бинаны, корылманы карап тикшерү турында хәбәр ителә.

Бинада, корылмада аварияле хәлләр барлыкка килү яисә бинаның, корылманың җимерелү куркынычы барлыкка килү турында гариза кергән очракта, вакәләтле орган тарафыннан тиз арада теләсә нинди ысул белән гариза бирүчегә һәм бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы затка бинаны, корылманы карап тикшерү турында хәбәр ителә.

11. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү барышында түбәндәгеләр башкарыла:

1) төзелеш конструкцияләренең (техник диагностиканың заманча чараларын кулланып), инженерлык-техник тәэмин итү системаларының, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең һәм аларның элементларының төзеклеген тикшерү;

2) үткәрелгән карап тикшерүләрнең, контроль тикшерүләрнең һәм (яки) бинаның, корылманың нигезенә, төзелеш конструкцияләренә, нженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә һәм нженерлык-техник тәэмин итү системаларына, аларның элементларына мониторинг даталары һәм нәтиҗәләре турында, бинага, корылмага техник хезмәт күрсәтү буенча башкарылган эшләр турында, бинаны, корылманы эксплуатацияләү процессында ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында, башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрнең даталары һәм эчтәлеге турында, әлеге кимчелекләрне бетерү турында мәгълүматлар кертелгән бинаны, корылманы эксплуатацияләү журналын тикшерү;

3) күпфатирлы йортка техник документация белән танышу, күпфатирлы йортны карап тикшерү очрагында күпфатирлы йортны эксплуатацияләү буенча инструкцияне кертеп;

4) объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына техник регламент таләпләре,

карап тикшерелә торган объектның проект документациясе таләпләре нигезендә техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтелүен бәяләү өчен кирәк булган башка чаралар.

12. Бинаны, корылманы карап тикшерү вакыты гаризаны теркәгән көннән соң 20 көн тәшкил итә, биналарда, корылмаларда аварияле хәлләр барлыкка килү яисә биналарның, корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килү турында гариза кергән очракта – гариза теркәлгәннән соң 24 сәгатьтән артык түгел.

13. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бинаны, корылманы карап тикшерү турындә бәяләмә төзелә.

Бинаны, корылманы карап тикшерү турында бәяләмәгә каралган бинаның, корылманың техник диагностика материаллары һәм бинаны, корылманы карап тикшерү барышында рәсмиләштерелгән башка материаллар теркәлә.

14. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү барышында объектларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына техник регламент таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре бозылу ачыкланган очракта, биналарны, корылмаларны карап тикшерү бәяләмәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар турында тәкъдимнәр бәян ителә.

15. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү бәяләмәсенең күчермәсе гариза бирүчегә, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы затка расланган көннән өч көн эчендә юнәлтелә яки күрсәтелгән затларга имзаларын алып тапшырыла, карап тикшерү биналарда, корылмаларда аварияле хәлләр барлыкка килү яисә биналарның, корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килү турында гариза нигезендә үткәрелгән очракта – гариза бирүчегә, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы затка биналарны, корылмаларны карап тикшерү көнендә тапшырыла.

16. Биналарны, корылмаларны карап тикшерү барышында объектларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына техник регламент таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре бозылу ачыкланган очракта, вәкаләтле орган биналарны, корылмаларны карап тикшерү бәяләмәсенең күчермәсен расланган көннән өч көн эчендә бинаны, корылманы эксплуатацияләүне туктатып тору турында, әлеге затны җаваплылыкка тарту турында мәсьәләне хәл итү компетенциясендә булган органга юнәлтә.

17. Биналарның, корылмаларның карап тикшерелүе турында мәгълүматлар вәкаләтле орган тарафыннан алып барылган биналарны, корылмаларны карап тикшерүне исәпкә алу журналына кертелә.

18. Әгәр биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә федераль законнар нигезендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырылса, биналарны, корылмаларны карап тикшерү уздырылмый.

Бу очракта биналарны, корылмаларны эксплуатацияләүгә Россия Федерациясе законнары таләпләре бозылу турында, биналарда, корылмаларда аварияле хәлләр барлыкка килү яисә биналарның, корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килү турында гариза,

теркәлү көненнән җиде көн эчендә, биналарны, корылмаларны эксплуатацияләү барышында федераль законнар нигезендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарга юнәлтелә.

Гариза бирүчегә гариза теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә биналарны, корылмаларны карап тикшерүдән баш тарту турында һәм гаризаны биналарны, корылмаларны эксплуатацияләү барышында федераль законнар нигезендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарга юнәлтү турында язма хәбәрнамә җибәрелә.

## 3. Нигезнамәне үтәүне контрольдә тоту

19. Нигезнамәне үтәүне контрольдә тоту Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелеш һәм торак үсеше идарәсе тарафынна гамәлг ашырыла.